ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МАЛОКИРМЕНСКОГО СЕЛЬСКОГО
ПОСЕЛЕНИЯ МАМАДЫШСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.З.Закирова, д.47, с. Малые Кирмени,
Мамадышский район,
Республика Татарстан, 422172

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МАМАДЫШ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ КЕЧЕ КИРМӘН АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ
З.Закиров ур., 47 нче йорт, Кече Кирмән авылы,
Мамадыш районы,
Татарстан Республикасы,422172

тел.(факс): (85563) 2-96-17; e-mail: MKir.Mam@tatar.ru, www:mamadysh.tatarstan.ru

Карар — Постановление

№ 2 — «30 » январь 2023 ел

Татарстан Республикасы Мамадыш
муниципаль районы Кече Кирмән авыл җирлеге
җирлекара күмү урыннарында
җирләү буенча гарантияләнгән исемлек
нигезендә хезмәт күрсәтү бәясен
раслау турында

«Күмү һәм җирләү эше турында» 1996 елның 12 нче гыйнварындагы 8-ФЗ санлы Федераль законның 9 статьясының 3 пункты һәм 12 статьясының 3 пункты (үзгәрешләр һәм өстәмәләрне исәпкә алып), «Татарстан Республикасында «Күмү һәм җирләү эше турында» Федераль законны тормышка ашыру чаралары хакында» 2007 елның 18 маендагы 196 нчы карары нигезендә, Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Кече Кирмән авыл җирлеге Башкарма комитеты к а р а р б и р ә:

1. Мамадыш муниципаль районы Кече Кирмән авыл җирлеге җирлекара күмү урыннарында җирләү буенча гарантияле исемлек нигезендә хезмәт күрсәтү бәясен 1 нче һәм 2 нче кушымталар нигезендә 7793,48 сум күләмендә билгеләргә һәм 2023 нче елның 1 февраленнән гамәлгә кертергә.

2. Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Кече Кирмән авыл җирлеге Башкарма комитетының 2022 елның 31 январендәге «Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Кече Кирмән авыл җирлеге җирлекара күмү урыннарында җирләү буенча гарантияләнгән исемлек нигезендә хезмәт күрсәтү бәясен раслау турында » № 4 карарын гамәлдән чыкты дип танырга.

3. Бу карарны массакүләм мәгълүмат чараларында («Нократ ("Вятка")) бастырып чыгагрырга һәм Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районының рәсми сайтында (http://mamadysh.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында урнаштырырга(pravo.tatarstan.ru).

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Җитәкче /Х.Х.Мубаракшин/

Татарстан Республикасы
Мамадыш муниципаль районы
Кече Кирмән авыл җирлеге
Башкарма комитетының
31. 01.2023 ел , № 2 карарына
1 нче № кушымта

2023 елның 1 февраленнән Татарстан Республикасы
Мамадыш муниципаль районы Кече Кирмән авыл җирлеге җирлекара күмү урыннарында җирләү буенча
гарантияле исемлек нигезендә тормыш иптәше, якын туганнары, законлы вәкиле үлгән (һәлак булган) очракта, хезмәт күрсәтү бәясе

| Хезмәт күрсәтү атамасы | Хезмәт күрсәтү бәясе (сумнарда) |
| --- | --- |
| 1. Җирләү өчен документлар әзерләү | 0,0 |
| 2. Гүргә иңдерүгә кабер такталары, табут һәм башка предметлар бирүгә һәм китерүгә | 3585,04 |
| 3. Мәетне (мәет калдыкларын) зиратка алып килүгә | 934,13 |
| 4. Җирләү (кабер казу һәм күмү) | 3274,31 |
| Барлыгы | 7793,48 |

Татарстан Республикасы
Мамадыш муниципаль районы
Кече Кирмән авыл җирлеге
Башкарма комитетының
30. 01.2023 ел, № 2 карарына
2 нче № кушымта

2023 елның 1 февраленнән Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Мамадыш шәһәре җирлекара күмү урыннарында җирләү буенча гарантияле исемлек нигезендә, тормыш иптәше, якын туганнары, законлы вәкиле булмаган очракта, хезмәт күрсәтү бәясе

| Хезмәт күрсәтү атамасы | Хезмәт күрсәтү бәясе (сумнарда) |
|---|---|
| 1. 1.Җирләү өчен документлар әзерләү | 0,0 |
| 2. Мәетне киендерү, кәфенләү | 1112,23 |
| 3.Гүргә индерүгә кабер такталары, табут һәм башка предметлар бирүгә һәм китерүгә | 2574,60 |
| 4.Мәетне (мәет калдыкларын) зиратка алып килүгә | 953,05 |
| 5. Җирләү (кабер казу һәм күмү) | 3153,60 |
| Барлыгы | 7793,48 |